РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21 май 2025 ел № 17

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең 2022 елның 12 октябрендәге 42 номерлы карары белән расланган Генераль планына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше Кодексының 24 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 14 статьясындагы беренче өлешенең 20 пункты нигезендә, 2025 елның 27 мартында үткәрелгән гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәр Советының 2022 елның 12 октябрендәге 42 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең Генераль планына кертелә торган үзгәрешләрне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре Уставында билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерергә, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр төзелеше сәясәте һәм архитектура идарәсенә Россия Федерациясе территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында расланган документны урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын үстерү буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры вазыйфаларын
башкаручы, Мэр урынбасары М.В. Камелина

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН